КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 29 декабрь г.Казань № 1727

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукын алу өчен аукционда катнашуга гариза формасын раслау турында» 2012 ел, 20 октябрь, 876 нчы карары үз көчен югалткан дип тану хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «ЭКОлидер» еллык республика конкурсын үткәрү турында» 2004 ел, 28 июнь, 307 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 ел, 27 июнь, 256 нчы; 2010 ел, 9 март, 124 нче; 2017 ел, 24 ноябрь, 900 нче; 2022 ел, 27 июнь, 606 нчы; 2023 ел, 10 август, 967 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «ЭКОлидер» еллык республика конкурсын үткәрү турындагы нигезләмәгә, 4.2 пунктның җиденче абзацында «санын киметеп» сүзләрен «азайтып» сүзенә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында тискәре метеорологик шартлар чорларында атмосфера һавасына зарарлы (пычраткыч) матдәләр чыгаруны җайга салу эшләрен оештыру турында» 2012 ел, 22 май, 407 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 29 апрель, 354 нче; 2021 ел, 21 гыйнвар, 18 нче; 2021 ел, 17 ноябрь, 1097 нче; 2023 ел, 10 август, 967 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә «зарарлы (пычраткыч)» сүзләрен «пычраткыч» сүзенә алмаштырырга;

2 пунктта:

дүртенче абзацта «зарарлы (пычраткыч)» сүзләрен «пычраткыч» сүзенә алмаштырырга;

сигезенче абзацта «зарарлы (пычраткыч)» сүзләрен «пычраткыч» сүзенә алмаштырырга;

унынчы абзацта «зарарлы (пычраткыч)» сүзләрен «пычраткыч» сүзенә алмаштырырга;

3 пунктның өченче абзацында «зарарлы» сүзен «пычраткыч» сүзенә алмаштырырга.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы коллегиясе санын һәм составын раслау турында» 2019 ел, 1 февраль, 59 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 5 ноябрь, 1016 нчы; 2021 ел, 13 февраль, 76 нчы; 2021 ел, 13 октябрь, 974 нче; 2022 ел, 25 февраль, 162 нче; 2022 ел, 17 август, 849 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгы коллегиясе составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

коллегия составыннан А.М.Шиһаповны, А.П.Шлычковны чыгарырга;

коллегия составына түбәндәгеләрне кертергә:

| | |
|---|---|
| Газиева Наилә Хәмид кызын | Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет рәисен (килешү буенча) |
| Галиев Ренат Марат улын | Татарстан Республикасы Рәисе ярдәмчесен (килешү буенча) |
| Тугушев Алмаз Абзал улын | Татарстан Республикасы экология һәм табигать ресурслары министры урынбасарын; |

Илдар Ирек улы Гыйльметдиновның вазыйфа исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы экология һәм табигать ресурслары министрының беренче урынбасары»;

Рифгать Роальд улы Шаһидуллинның вазыйфа исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт фәнни бюджет учреждениесенең Экология һәм җир асты байлыкларыннан файдалану проблемалары институты директоры».

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукын алу өчен аукционда катнашуга гариза формасын раслау турында» 2012 ел, 20 октябрь, 876 нчы карары үз көчен югалткан дип танырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин